


ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 8 (23) 27 АПРЕЛЯ 2010

ВЕСТИ, СОБЫТИЯ, РЕПОРТАЖИ

# Приветствуем участников конференции!

28 апреля в селе Асекеево, в Доме культуры, в 11 часов, откроется Седьмая конференция татарской национально-культурной автономии района.

Цифры и факты:

— Татарский общественный центр Асекеевского района создан в 1994 году. В 1998 году ТОЦ преобразован в местную татарскую национально-культурную автономию (ТНКА) Асекеевского района. Однако, первые попытки создания национального объединения татар Асекеевского района были еще 1989 году.

— За последние годы создано семь первичных организаций ТНКА в селах и деревнях Асекеевского района.

— 13 марта 2009 года создана Ассоциация национально-культурных объединений «Бердэмлек». В нее вошли: ТНКА Асекеевского района, ТОЦ, «Туган тел» города Бугуруслана, культурно-просветительского общество «Туган тел» Похвистневского района Самарской области.

— За 2007-2009 годы в автобусных экскурсиях, организованных ТНКА, в Казани и других памятно-исторических местах Татарстана, побывали более 80 взрослых и детей — жителей Асекеевского района.

— По направлению ТНКА, за три последних года, в летних оздоровительных лагерях Татарстана отдохнули 85 детей.

— По направлению ТНКА и при содействии Всемирного конгресса татар в высшие учебные заведения Татарстана поступило за отчетный период пятеро выпускников школ.

— Делегатами седьмой конференции национально-культурной автономии избрано шестьдесят человек.

# Открыли подписку

Редакция объявляет о начале подписки на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край» на второе полугодие 2010 года.

Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.

Подписаться можно в любом почтовом отделении или непосредственно у почтальонов.

**Индекс издания 53167.**
**Цена за полугодие — 94 рубля 50 копеек.**

# Субботник в саду Джалиля

В 2005 году в селе Асекеево был установлен памятник Мусе Джалилю. С тех пор парк, где установлен мраморный монумент символизирующий «Моабитскую тетрадь», в народе называют «Садом Джалиля».

В прошедшую пятницу, в рамках общерайонного «субботника», парк Джалиля был приведен в порядок силами татарской автономии, школьников и работников энергопредприятия.

Парк и сам монумент под постоянной опекой ТНКА. Зимой дорожки очищаются от снега, весной и летом территория благоустраивается.

# ХӨРМӘТЛЕ МИЛЛӘТТӘШЛӘР!

Быел без Бөек Җиңүнең 65 еллыгын билгеләп үтәбез. Бу Җиңү зур корбаннар аша килде һәм менә 65 ел инде илебез халкы тыныч тормышта яши. Дүрт ел сугыш дәвамында халкыбыз тудырган зур батырлыклар һәм кичергән зур газаплар 65 ел буена да, 100 ел буена да онытылырлык түгел. Без бу Җиңүне гомер буе исебездә тотачакбыз. Каһарманнар даны мәңгелек.

Кадерле ветераннар! Илебез күгенең 65 ел буена аяз булуы белән без сезгә бурычлы һәм рәхмәтле. Озын гомер, тыныч көннәр насыйп булсын барыбызга да.

**Илдус ДӘҮЛӘТОВ,**
**өлкә Закончыгару җыелышы депутаты.**



**Ветерана войны и труда ШАВАЛЕЕВА Габдуллу Шавалеевича (на снимке) знают не только в Асекеево. Несмотря на свой солидный возраст, а ему недавно исполнилось девяносто два года, он по-прежнему в строю, активно участвует в общественной жизни района. Он второй секретарь райкома КПРФ, активист татарской национально-культурной автономии. Вообще, человек не равнодушный. Ну а зимой он первым прокладывает лыжню за околицей, показывая молодежи пример любви к спорту и физической культуре. В этот юбилейный год Победы хочется поздравить славного ветерана и пожелать крепкого здоровья, бодрости и оптимизма.**

# Авылыбызның ветераны

Озакламый без 9 Май — Бөек Җиңү бәйрәмен билгеләп үтәбез. Ә бүгенге көнне аңа зур әзерләнү бара.

Үзенең 86 язын каршылый Зәкәрия Зөлкәрнәй улы Тухбатов — Бөек Ватан сугышы ветераны, Матвеевка районы Иске Әшер авылыннан.

Зәкәрия бабай шушы авылда туып үскән. Барлыгы 4 класс тәмамлаган һәм колхозда төрле эшләрдә эшли башлаган. Сугыш башлангач аны армия сафларына алып китәләр Ерак Көнчыгышка Диңгез флоты хезмәтенә. Аның белән бергә Тәүфик Тазиев, Исрафил Латыпов, Госман Шангареев сугыш эчендә кайнаганнар.

«Бу ачы, кайгылы елларны искә дә төшерәсе килми»-ди, күз яшьләрен сөртеп Зәкәрия бабай. «Безнең буынга кайгылы вакытлар кичерергә туры килде. Сугыш кырларында бик күп яшь солдатлар һәлак булып калдылар», — дип сүзен дәвам итте ветеран. 1948 елны З.З.Тухбатов туган авылына Иске Әшергә кайта. Бераздан соң ул Матвеевка МТСының тракторчылар курсын тәмамлый һәм колхозда эшен дәвам итә. 34 ел ул авыл хезмәтендә эшли. Күп тырышлыгы өчен Зәкәрия абыйны истәлекле бүләкләр, рәхмәт хатлары белән бүләклиләр. Хәләл җефете Бибисара апа белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр һәм 62 ел бергә гомер кичерәләр. Бибисара апа да шулай ук колхозның төрле эшләрендә эшләп хаклы ялга чыкты һәм хезмәт ветераны.

Без, яшь буын балалары, горурланып яшибез шундый тырыш авылдашларыбыз барлыкка. Телибез аларга сәламәтлек, ак бәхетләр, илләр тыныч һәм өстәлләр ризык белән мул булсын!

**Артур НИЗАМОВ, Матвеевка районы.**

# Тукай — безнең йөрәкләрдә

26 апрельдә татар халкыбыз үзенең иң яраткан шагыйре Габдулла Тукайның туган көнен билгеләп үтә. Ул көннәрдә аның иҗатына багышланган кичәләр, очрашулар уздырыла. Шул кичәләрнең берсе Әсәкәй район балалар китапханәсендә үтте.

«И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Үзенең туган телгә булган мәхәббәтен татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай әнә шулай матур итеп әйтеп биргән. Чынлап та, туган телне чын мәгънәсендә ярату Туган илне, әткәң-әнкәңне ярату белән бер ул. Туган телне юкка гына ана теле дип атамаган шул халык!

Бөек әдип Габдулла Тукай туган телне ярата белеп яраткан. Г.Тукай туган телне, халыкча итеп, «туган тел, матур тел, әткәм-әнкәмнең теле»,- дип атаган. Шагыйрьнең туган телне яратуы, Туган илгә булган мәхәббәте белән үрелеп килә, аның аерылгысыз өлешен тәшкил итә»,-диеп башлады кичәне алып баручы Халисә Таваева, балалар китапханәсенең мөдире.

Теле булган халык кына бу дөньяга үз сүзен аяк терәп әйтә ала. «Телен югалткан-үлгән»,-ди халык. Хак әйтә.

Туган тел төшенчәсенә зур мәгънә салынган. Ул Ватан, туган җир, ата-ана сүзләре белән бер үк дәрәҗәдә тора торган бөек, изге һәм кадерле сүз. Ул телгә баланы башлап аның иң газиз кешесе — анасы өйрәтә, шул телдә аңа бишек җырлары җырлый, иркәли, юата.

Тел — бөтен халык казанышы, мәңнәрчә, миллионнарча кешеләрнең күп гасырлык иҗат җимеше. Тел — халыкның, милләтнең иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү — һәр кешенең изге бурычы.

Әйе, Габдулла Тукай — туган телебезнең сихри моңнарын бар нечкәлекләре белән безгә җиткерде. «Туган тел» шигырен татар халкы үз теләнә гимн итеп сайлады.

Балалар шагыйрьнең шигырьләрен сөйләделәр, рәсемнәрен күргәзмәгә куйдылар. «Тукай — безнең йөрәкләрдә» кичәсе Г.Тукайның «Туган тел» җыры белән тәмамланды.

***Ләлә* БАҺАУТДИНОВА,**
**балалар китапханәчесе, Әсәкәй авылы.**